

Әлеге сорауга жавапны Мордовия Республикасында Россия Федерациясе моселманнарынын Үзәк диния нәзарәте тулы хокуклы вәкиле Рафаэль хазрәт Манюров болай дип сойләде.
Рәжәб аенда Рәгаиб һәм Мигъраж дип аталган мобарәк кичәләр бар.

15-16 январендә Мигъраж кичәсе иде, рәжәб аенын 26-27нче коне. Ботен кешелек доньясына рәхмәт һәм шәфкать итеп жибәрелгән Пәйгамбәребез Мохәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнен жиде кат күккә, Аллаһы Тәгалә хозурына ашуы белән бәйле бәйрәм. Шушы кичәдә Аллаһы Тәгалә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне Үзенен хозурына чакырып, үткән пәйгамбәрләр белән күрештереп, исәпсез хикмәт һәм олы могжизалар күрсәтте. Мигъраж кичәсендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә оч бүләк булды. Биш вакыт намаз уку бу кичәдә фарыз ителә. Ислам фәлсәфәсе буенча, бу кичәдә Коръәннен “Бәкара” сүрәсенен 285-286нчы һәм “Исра” сүрәсенен 23-29нчы аятьләре ингән. Пәйгамбәребезгә Кыямәт конендә омметен яклау хокукы бирелде, ягъни Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Кыямәт конендә Аллаһы Тәгаләдән гонаһлы моселманнарга ярдәм биреп, аларны газаплардан коткаруны сораячак.
2-3 февраль – Бәраәт кичәсе, шәгъбан аенын 14-15нче коне. Бәраәт кичәсе гонаһтан, явыз нияттән, золым гамәлдән, адәм вә хайван рәнжетүдән, жәзадан коткарылу, хәрамнан арыну мәгънәсен анлата. Шәригатьчә әйткәндә, Бәраәт – ул гафу-мәгъфирәт, истигъфар кичәсе. Бәндәләрнен бер еллык бәхете шушы кичәдә тәгаен кылына. Шунын

очен ул изге кичәләрдән санала.
Бәраәт – ул тәvбә кичәсе. Шунын очен дә Пәйгамбәребез Мохәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм vзенен мобарәк хәдисендә: “Әй, адәмнәр, ашыгыгыз намаз укырга, намазнын вакыты vтмәстән әvвәл”, дип, оммәтенә әйтеп калдырды. Рәсvлебез Бәраәт кичәсендә фәкать гыйбадәт вә намаз белән мәшгуль булган. Раббыбызнын рәхмәтен сорап догалар кылуны vзенә гадәт иткән һәм: “Шәгъбан аенын 15нче кичәсе кергәч, тондә гыйбадәт кылып, кондезендә ураза тотыгыз”, – дип, оммәтен ондәгән.
19 февраль – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган кон. Пәйгамбәребез Мохәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: “Исегездә тотыгыз: рәҗәб – Аллаһы Тәгаләнен ае. Бу айда берәрегез бер кон булса да ураза тотса, Аллаһы Тәгалә аннан разый булыр”, – дигән.
16-17 март – Кадер кичәсе, Рамазан аенын 26-27нче коне. Коръән Кәримдә искә алынган ин моһим, ин әһәмиятле кичә. Бу тон – язмыш хәл ителә торган, коч-кодрәт тоне. Ул Рамазан аенын 26нчы коненә туры килә. Рамазан аенын сонгы оч коненен тоннәре дә изге санала. Пәйгамбәребез Мохәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренә: “Кадер кичәсен рамазан шәриф аенын ахыргы ун коненен бер так (нечетный) кичәсендә эзләгез”, – диде. Ягъни 21, 23, 25, 27 һәм 29нчы кичәдә булуы ихтимал. Шушы кичәләрдә аеруча кvбрәк дога, истигъфар, гамәл вә гыйбадәт белән шогыльләнv кирәк. Әлеге һәм Рамазан ае тәмамланыр алдыннан булучы башка тоннәрдә, йокламыйча, Аллаһы Тәгаләдән ярлыкауны теләп-ялварып, намаз укып чыгалар. Нәкъ менә кадер тонендә Коръән Кәримнен топ носхәсе, Аллаһы Тәгаләнен корси-тәхете остеннән алынып, Җәбраил фәрештә тарафыннан кvкнен жиргә якын катына кvчерелә һәм, шуннан торып, анын эчтәлеге 22 ел дәвамында Пәйгамбәребез Мохәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә индерелә.
20 март – Ураза бәйрәме, шәvвәл аенын 1нче коне. Моселманнарнын ике зур бәйрәменен берсе. Моэмин-моселманнар Рамазан аенда ураза тота, ай дәвамында сәхәргә тора, калебләрен Хак Тәгаләгә юнәлтеп, гафу итvен сорап, Ана ялвара, тәvбә итә, дога һәм намаз укый. Кулларын, аякларын, телләрен, кvзләрен һәм колакларын динебезгә хәрам булган нәрсәләрдән тыярга, аяклары начар юлдан йормәскә, куллар жәбер-золым кылмаска, кvзләр әшәкелекне кvрмәскә, колаклар әхлаксыз сvзләрне тынламаска, телләр гайбәт сойләмәскә тырыша. Шул рәвешле алар Аллаһка ярау имтиханын vтә. Шәvвәл аенын беренче конендә кояш сонге буе кvтәрелгән вакытта гает намазы укыла, вәгазь сойләнә. Шәvвәл аенын оч коне тулысынча бәйрәм санала.
Шулай итеп, изге Рамазан ае 19 февральдә башлана – бу уразанын беренче коне булачак. Ураза 29 кон дәвам итә, анын сонгы коне - 19 март. Икенче конне, 20 мартта, моселманнар Ураза бәйрәмен билгеләп vтәчәк. Ураза вакытында моселманнар тан атканнан алып кояш баеганчыга кадәр ашау-эчvдән тыелып тора. Моннан тыш, изге Рамазан аенда ир-атларга, тонге намаздан сон, тәравих намазын укыр очен мәчеткә бара. Шулай ук Рамазан аенда Коръән укырга, кvбрәк вакытны гыйбадәт кылып vткәрергә һәм изге гамәлләр кылырга: мохтажларга ярдәм итәргә һәм сәдака таратырга кинәш ителә.

**Наилә НАСЫРОВА**